үзе үлсә дә истәлекләре белән безнең арада яшәгән кебек. Чын татар ирләренә хас булган зур эшләр башкарып киткән.

Хәзерге инновацион технологияләр заманында җәмгыятьтә барган үзгәрешләр бүгенге көн укучысына яңадан-яңа бурычлар куя. Социаль каршылыклар күп булган җәмгыятьтә без, XXI гасыр балалары, Г. Ахунов әсәрләре аша тәрбияләнсәк, практик яктан да, рухи яктан да тормышка әзер булыр идек.

Г.Ахуновның тормышына, иҗатына истәлекләр гаять күп язылган. М.Хәсәнов, М. Мәһдиев, Т.Галиуллин, Ф.Галимуллин тарафыннан язылган истәлекләр миңа аеруча ошады. Мин бу эшне язганда шушы истәлекләргә таянып эшләп, үзем өчен күп мәгълүмат тупладым. Алар миңа дөрес юнәлеш бирделәр, читкә китмәскә булыштылар.

Әдәбият:
1.Гариф Ахунов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
2. Ахунов Гариф. – Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2005.
3. Ахунов Гариф. Без бит Арча яклары. – Казан. Татар. кит. нәшр., 1979.
4. Азат хатын. – 1975 – №9.

***Сания Ильяс кызы Габитова,***
*Балтач районы Субаш төп гомуми белем*
*мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## Күркәм гадәтләр

Әдәбиятыбызны Арча ягыннан чыккан имәндәй баһадир әдипләре Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Гариф Ахуновсыз күз алдына китерү кыен. Ә менә Гариф Ахуновны язган әсәрләре – китаплары буенча да, әдәби хәрәкәтне оештыруда кылган гамәләре буенча да, Равил Фәйзуллин әйткәнчә, мөгаен, татар совет әдәбияты классигы дип атау дөрес буладыр [1].

Гариф Ахуновны мин үзем мәктәп елларында укып танышкан “Хәзинә” романы аша белә башладым. Тора-бара татар теле һәм әдәбияты укытучысы булгач, кызыксынуым артты. Миндә саллы язучылар турында язылган мәкаләләр, төрле язмаларны туплап бара торган гадәт бар. Бервакыт кулыма 1995 елгы “Ватаным Татарстан” газетасы килеп керде. Анда Гариф аганың “Үзем өчен” дигән папкасыннан берничә шигыре бастырылган иде. Проза язучы әдипнең күңелендә һәрвакыт шигъри кыл зыңлап торган күрәсең. Язган шигырьләре белән танышкач, аның тормышы тагын да кызыклырак тоелды. Бигрәк тә мине гаиләсе, тормыш иптәшенең кем булуы, балалары кызыксындырды. Укучыларны да дәрестә, язучы иҗаты белән таныштырганда, нәкъ шулар кызыксындыра. Бәхетле кешеләрдә генә була торган эчке илһамлануын, тормыш ләззәтенә сөенүен шигырь юллары аша биргән. Аннан 1998 нче елгы бер газетада Гариф Ахуновның үзе язган “Беренче тойгылар” [2] дип аталган язмасын укуым хәтердә. Анда тормыш